**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 июль № 531

г. Казань

Казан шәһәрендә спортның су төрләре буенча 2015 елгы XVI дөнья чемпионатын һәм «Мастерс» категориясендә спортның су төрләре буенча XVI дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру чорында нурланышлы, химик һәм биологик саклауны һәм тикшерүдә тотуны оештыру турында

Казан шәһәрендә спортның су төрләре буенча 2015 елгы XVI дөнья чемпионатын һәм «Мастерс» категориясендә спортның су төрләре буенча XVI дөнья чемпионатын (алга таба – Дөнья чемпионаты) әзерләү һәм уздыру чорында нурланышлы, химик һәм биологик саклауны һәм тикшерүдә тотуны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

нурланышлы, химик һәм биологик саклау һәм тикшерүдә тоту көчләре төркеме составын;

нурланышлы, химик һәм биологик характердагы вакыйгалар (гадәттән тыш хәлләр) килеп туган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән багланышлары тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, ә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының транспорттагы

Казан чик буе идарәсенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә, Федераль таможня хезмәте Идел буе таможня идарәсенең Татарстан таможнясына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсенең «Поволжье» чик буен тикшерүдә тоту отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пунктына, Экология, технология һәм атом күзәтчелеге буенча Федераль хезмәтнең Идел буе идарәсенә, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә, «Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә, «Татар төбәкара ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә, «РосАтом» дәүләт корпорациясенең «РосРАО» радиоактив калдыклар белән эш итүче предприятие» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Идел буе территориаль округы» филиалы Казан бүлегенә, Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүендә тоту челтәре составына керүче Казан шәһәре учреждениеләренә, «Спорт проектларының башкарма дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага, Дөнья чемпионаты объектлары һәм нигезләрендә гражданнар оборонасы объектлары төзелгән Татарстан Республикасы оешмалары, нурланышлы, химик һәм биологик яктан куркыныч объектлар, аэропортлар, автовокзаллар, елга портлары һәм тимер юл станцияләре җитәкчеләренә (милекчеләренә) гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә:

үз вәкаләтләре кысаларында нурланышлы, химик һәм биологик хәлне мониторинглауны;

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасының көндәлек идарә итү органнары белән үзара багланышларны һәм әлеге карар белән расланган нурланышлы, химик һәм биологик саклау һәм тикшерүдә тоту көчләре төркеме составына көчләр һәм чаралар бирүне;

Казан шәһәре территориясендә урнашкан нурланышлы, химик һәм биологик яктан куркыныч объектларда агулану, җимерелү (авария) шартларында, шулай ук Дөнья чемпионаты объектларында яки халык күп җыелган урыннарда булуы ихтимал террорчылык актлары нәтиҗәсендә мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне бетерү барышында үз вакытында җавап кайтаруны һәм куелган бурычларның үтәлешен тәэмин итүне.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

медицина оешмаларында гадәттән тыш хәлләр очракларына медицина ресурслары резервларын, шул исәптән үзенчәлекле фармакотерапия препаратларын инвентарьлаштыру үткәрергә һәм яңартырга;

нурланышлы, химик һәм биологик агулану очрагында халыкка медицина ярдәме күрсәтүне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына үз вәкаләтләре кысаларында әйләнә-тирә мохитны мониторинглауны гамәлгә ашырырга.

5. Тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына аеруча мөһим, куркыныч ихтималы булган объектларның һәм тереклек тәэмин итү объектларының милекчеләре белән бергә Дөнья чемпионатын үткәрү башланганчы үзенең куркынычсызлык көчләре яисә шартнамә нигезендә ведомстводан тыш сак хезмәте нарядлары ярдәмендә Казан шәһәре территориясендә урнашкан күрсәтелгән объектлар сагын көчәйтергә;

Федераль таможня хезмәте Идел буе таможня идарәсенең Татарстан таможнясына Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсенең «Поволжье» чик буен тикшерүдә тоту отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм аэропортлар, автовокзаллар, елга портлары, тимер юл станцияләре җитәкчеләре (милекчеләре) белән берлектә үз вәкаләтләре кысаларында күрсәтелгән объектларга һәм йөк терминалларына пассажирлар һәм йөкләр килгәндә нурланышлы, химик һәм биологик тикшерүдә тоту оештырырга;

«Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитны мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә Казан шәһәре территориясендә атмосфера һавасын, коры җирнең өстәге суларын (Кабан күле, Казансу елгасы, Куйбышев сусаклагычы) мониторингларга, стационар күзәтү постларында нурланышны мониторингларга (гамма-нурланышның экспозицион үлчәме куәтен, кушылган бета-активлыкны, нурланышлы йод микъдарын), нәтиҗәләрен тиешле хезмәтләргә тапшырырга;

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге буенча Федераль хезмәтнең Идел буе идарәсенә:

куркыныч технологик производстволарның һәм химик профильдәге җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы һәм авариягә каршы саклануы хәлен бәяләүне гамәлгә ашырырга, химик профильдәге куркыныч җитештерү объектларында аварияләрнең сәбәпләрен техник тикшерү үткәрергә;

күзәтү чаралары кысаларында шартлау-янгын куркынычы булган һәм химик яктан куркыныч җитештерү объектларыннан файдаланучы предприятиеләр җитәкчеләреннән Дөнья чемпионатын үткәрү чорында куркынычсыз файдалану шартларын канәгатьләндерми торган производстволарны һәм техник җайланмаларны файдаланудан чыгаруны, файдалану нормативлары срогын эшләп бетергән, сәнәгать куркынычсызлыгы экспертизасының уңай бәяләмәсе булмаган техник җайланмаларның эшләвен рөхсәт итмәүне, шулай ук предприятиеләр җитәкчеләреннән һәм белгечләреннән производстволарны һәм объектларны куркынычсызлык таләпләренә туры китерүне, аларның аварияләргә каршы торучанлыгын, шул исәптән консервация шартларында, күтәрүне, куркыныч

матдәләрне саклау һәм эш итү технологик процессларына санкцияләнмәгән катнашуны булдырмас өчен куркыныч җитештерү объектларын предприятиеләр территорияләренә чит затлар керүдән саклау чараларын көчәйтүне таләп итәргә;

куркыныч матдәләрне саклау һәм эш итү технологик процессларына санкцияләнмәгән катнашуны булдырмас өчен куркыныч җитештерү объектларын предприятиеләр территорияләренә чит затлар керүдән саклау чараларын көчәйтергә;

сәнәгать куркынычсызлыгы, куркыныч җитештерү объектларын террорчылык күренешләреннән физик саклау таләпләренә җавап бирми торган производстволарны төзекләндерү, яңадан коралландыру чараларын тормышка ашыру барышына нәтиҗәле тикшерү һәм күзәтчелек урнаштырырга;

Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә:

халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуларны кисәтү, ачыклау һәм аларга юл куймауга, инфекцияле һәм массакүләм инфекцияле булмаган авыруларны (агулануларны) профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар күрергә;

биологик һәм химик куркынычларны фаразлау һәм халыкның һәм әйләнә-тирә мохитның биологик һәм химик куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча ашыгыч санитар-эпидемиягә каршы чаралар күрү максатында әйләнә-тирә мохитның антропоген факторларын мониторинглау үткәрергә;

инфекцияле авыруларны мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

кешеләр күп җыела торган объектларның, шул исәптән Дөнья чемпионаты объектларының санитар-эпидемиологик хәлен тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә;

биологик һәм химик куркынычларның кискен үсүенә, инфекцияле авырулар һәм масссакүләм инфекцияле булмаган авырулар кабынуына оператив җавап кайтарырга;

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә «Татар төбәкара ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе белән берлектә:

ветеринария һәм фитосанитария тикшерүе (күзәтчелеге) үткәрелергә тиеш килүче йөкләргә һәм Дөнья чемпионаты объектларына ветеринария-санитария һәм фитосанитария тикшерүен көчәйтергә;

Дөнья чемпионатын үткәрүдә катнашуга аккредитацияләнгән җәмәгать туклануы объектларында терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясе куркынычсызлыгын мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

«Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә:

Дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү чорында нурланышлы, химик һәм биологик тикшерүне гамәлгә ашырырга;

буйсынган бүлекчәләрне комплектлауны, җиһазлауны, кирәк-ярак булдыруны һәм әзерләүне, нурланышлы һәм химик тикшерүдә тотуның техник чараларын

тикшерүне оештырырга;

Татарстан Республикасы прокуратурасына Идел буе транспорт прокуратурасының Татар транспорт прокуратурасы белән берлектә, федераль законнар таләпләрен исәпкә алып, Дөнья чемпионаты чараларын һәм объектларына хезмәт күрсәтүдә катнашучы, шулай ук куркыныч йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне урыннарга чыгып планнан тыш тикшерүләрне килештерергә;

«Спорт проектларының башкарма дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Дөнья чемпионатын үткәрү чорында лицензияләнгән саклау оешмалары хезмәткәрләрен «РАДЕКС-1503+» дозиметрлары белән кирәкле санда тәэмин итәргә һәм спорт чараларын үткәрү объектларындагы үткәрү пунктларында (карап бетерү чатырларында) дозиметрик тикшерүләр үткәрүне оештырырга;

«РосАтом» дәүләт корпорациясенең «РосРАО» радиоактив калдыклар белән эш итүче предприятие» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Идел буе территориаль округы» филиалы Казан бүлегенә:

мөмкин булган гадәттән тыш хәлләргә җавап бирү максатларында авария төркемен хәзерлеккә китерергә;

авария төркемнәрен комплектлауны, җиһазлауны, кирәк-ярак булдыруны һәм әзерләүне оештырырга;

радиоактив пычрану табылган объектларда (урыннарда) ионлаштыручы нурланыш (радиоактив матдә) чыганакларын алуны һәм алып чыгуны гамәлгә ашырырга;

«Средволгаводхоз» су хуҗалыгы буенча федераль дәүләт учреждениесенә һәм Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенә үз вәкаләтләре кысаларында су объектларын мониторингларга;

«Нәфис Косметикс» ачык акционерлар җәмгыятенә халыкны санитария эшкәртүе буенча эшләр үткәрү мөмкинлеге, шулай ук техниканы, биналарны һәм территорияләрне махсус эшкәртү максатларында зарарсызландыручы матдәләр запасын булдырырга;

Дөнья чемпионаты объектлары, аэропортлар, автовокзаллар, елга портлары һәм тимер юл станцияләре җитәкчеләренә (милекчеләренә) үзләре карамагында булган вокзаллар һәм портларны нурланышлы, химик һәм биологик тикшерү үткәрүне оештыру өчен кирәкле җайланмалар һәм җиһазлар белән җиһазларга;

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитетына нигезләрендә гражданнар оборонасы объектлары, зарарсызландыру командалары һәм территориаль штаттан тыш авария-коткару формированиеләре төзелгән Татарстан Республикасы оешмалары, шулай ук Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәренә керә торган учреждениеләр белән берлектә, үз вәкаләтләре кысаларында:

санитария эшкәртүе территориаль пунктларын, кием һәм техниканы махсус эшкәртү станцияләрен, шулай ук лабораторияләрне әзерлеккә китерергә;

штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен, зарарсызландыру командаларын, пунктларны, станцияләрне һәм лабораторияләрне комплектлаштыруны, коралландыруны, кирәк-ярак булдыруны һәм әзерләүне

оештырырга;

нурланышлы, химик һәм биологик тикшерүне оештырырга;

Дөнья чемпионатын үткәрү вакытында нурланышлы, химик һәм биологик куркыныч объектлар җитәкчеләренә (милекчеләренә):

Казан шәһәре территориясе буенча ионлаштыручы нурланышлы, нурланышлы, химик һәм биологик (бактериологик), аварияле химик куркыныч, агулы һәм шартлаткыч матдәләр ташуны туктатырга;

аварияле химик куркыныч матдәләр запаслары күләмен куәтен киметмичә җитештерүне тәэмин итү дәрәҗәсенә кадәр киметергә;

мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрдән саклау максатларында объектлы газ-коткару формированиеләрен әзерлеккә китерергә;

газ-коткару формированиеләрен һәм штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен комплектлаштыруны, коралландыруны, кирәк-ярак булдыруны һәм әзерләүне, нурланышны һәм химик тикшерүнең техник чараларын тикшерүне оештырырга;

объектлы газ-коткару формированиеләрен мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне локальләштерү һәм бетерү өчен җибәрергә;

Дөнья чемпионаты кунаклары һәм катнашучылары яшәгән кунакханәләр һәм урыннар җитәкчеләренә (милекчеләренә) үзләре карамагындагы кунакханәләрне һәм яшәү урыннары нурланышын тикшерүне үткәрүне оештыру өчен кораллар һәм җиһазлар белән җиһазландырырга.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына әлеге карар белән расланган Нурланышлы, химик һәм биологик характердагы вакыйгалар (гадәттән тыш хәлләр) килеп туган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән багланышлары тәртибе нигезендә эш итәргә, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына һәм оешмаларга эш итәргә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\531.doc